<table>
<tr><td>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МИЧАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br><br>5, Республика Татарстан, Сабинский район,<br>Село Старый Мичан , ул. Школьная ,<br>тел. (84362) 42-3-31</td><td>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИЧӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br><br>422055, Татарстан Республикасы, Саба районы,<br>Иске Мичән авылы., Мәктәп урамы, 12 йорт<br>тел. (84362) 42-3-31</td></tr>
</table>

e-mail: mich.sab@tatar.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ 26.02.2021 — КАРАР №7

Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 24 апрелендә 13 номерлы карары белән расланган агач һәм куаклар кисүгә, төпләүгә яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының 2021 елның 25 февралендә 7 номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мичән авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакындагы” карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы финанс Министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте Идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык Идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча берләштерелгән коллегиясенең 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»2019 елның 23 апрелендә 13 номерлы карары белән расланган агач һәм

куак кисүгә, төпләүгә яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пункттагы таблицаның икенче баганасына түбәндәге эчтәлекле 2) пунктча өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар-Россия ФСХ.»;

1.2. 2.8 пунктындагы таблицаның икенче баганасына түбәндәге эчтәлекле 5) пунктча өстәргә:

“5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

1.3. 3.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Башкарма комитет сәркатибе электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша җавап бирү турында сорау җибәрә:

1) Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлар).

2) Законнарны бозган өчен штрафлар, салымнар, җыемнар, пенялар һәм түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән сорау.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/michan адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мичән авыл
җирлеге башлыгы А.А.Гараев